ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

19 февраль 2026 ел

**КАРАР**

№ 1618

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы Карары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5772 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2593 номерлы, 2023 елның 22 декабрендәге 12417 номерлы, 2024 елның 28 августындагы 5579 номерлы, 2025 елның 23 гыйнварындагы 360 номерлы, 2025 елның 13 мартындагы 1934 номерлы Карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә юл хәрәкәте иминлеген арттыру» муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Юл хуҗалыгы (юл фондлары)» 0409 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 2 288 984,35 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 779 712,43 мең сум,

2025 ел – 911 609,33 мең сум.»;

2) кушымтада:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлында:

«2025» графасында «492 430,40» санын «911 609,33» санына алмаштырырга;

- 3 бүлектә «УЮЧның норматив техник халәтен ирешелгән дәрәҗәләрдә саклап тоту» юлында:

«Финанслау һәм финанслау чыганаклары 2025» баганасында «492 430,40» санын «911 609,33» санына алмаштырырга;

- 4 бүлекне яңа редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен 2 288 984,35 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2023 ел – 597 662,59 мең сум, 2024 ел – 779 712,43 мең сум, 2025 ел – 911 609,33 мең сум.».

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә https://nabchelny.ru адресы буенча Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы Р.Ф. Вилдановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Ф.Ш. Салахов